ЮЛЛАР, ЮЛЛАР...
Татарстанда юл программаларын тормышка ашыруга 60,5 миллиард сумнан артык акча тотылачак
> 2

ЧҮПЛЕ ЯЛ
Казанда меңнән артык кеше катнашында Идел ярларын чистарттылар
> 2

ӘХЛАК САГЫНДА
«Безнең авыл имамы» бәйгесе җиңүчеләре бүләкләнде
> 3

ИСӘНМЕСЕЗ! ИСӐММĂСЕЗ!
«Ватаным Татарстан» – каратайлар авылында
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 117 (28890) | Шимбә | 13 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

МӘКТӘП УЛ – ҮЗЕ БЕР ТЕАТР

БЕЛГЕЧЛӘР ЯШЬ УКЫТУЧЫЛАРГА ХӘЕР-ФАТИХА БИРДЕ

Мәгариф

«Мин ант итәм көчне кызганмаска!» Яңа уку елы алдыннан ел саен педагогик уку йортларын тәмамлаган яшь укытучылар әнә шундый ант бирә. Быел да Яшел Үзән районының Осиново бистәсендәге Карпов исемендәге лицейда узган чарада һөнәргә тугрылык сакларга вәгъдә иттеләр. Республикада ел саен белем йортларына 1 меңгә якын яшь белгеч эшкә килә. Тик күпмесенең сабырлыгы гомерлеккә калырга җитәр икән?

Яшьләргә хәер-фатихасын бирергә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да, башка танылган шәхесләр дә килгән иде. Тантанага КФУ, Алабуга, Чаллы педагогик вузларын тәмамлаган 250гә якын яшь мөгаллим чакырылган. Министр белдергәнчә, ел саен көллиятләрне тәмамлаучыларның 85 проценттан артыгы төпләнеп кала. Бүген республикада математика, физика, химия, биология, рус теле укытучыларына кытлык бар. Укытучыларның берничә фәнне бергә алып баруы нәтиҗәсендә әлеге проблема хәл ителә. Илкүләм проектлар, «Авыл укытучысы» кебек программалар да ярдәм итә. Тик без үз яшьләребезне тәрбияләргә тиеш.

– Аларны үз сафларыбызга кабул итү – матур бәйрәм. Яшьләр мәктәпне бизи. Организмны яшәртү бу, – диде Илсур Һадиулллин.

«Мәктәп ул – үзе бер театр, – дип дәвам итте ул сүзен. – Россия күләмендә һәр мәктәптә театр булырга тиеш, диләр. Әмма аны аерым оештырырга да кирәкми дип уйлыйм. Ишектән керүгә үк башлана театр. Укытучылар, укучылар... Кызык вакыйгалар, драмасы да бар. Иң мөһиме – трагикомедиясе генә булмасын. Балаларны яратып, елмаеп, күңелегездәге хисләрегезне бирергә тырышыгыз».

Уку йортларын тәмамлаучылар арасында беренче чирканчыкны алучы егет-кызлар да бар инде. Укыган вакытта ук мәктәпләргә эшкә кайткан алар. Әгерҗе районының Исәнбай авылы мәктәбендә физика-математика фәннәрен укытучы Рәмис Газизов та шундыйлардан. Бер ел элек үзе укыган мәктәпкә эшкә кайткан ул. Хәзер инде ул – дипломлы белгеч. Алабуга институтында максатчан программа буенча укыган. Димәк, үз төбәгендә биш ел эшләргә тиеш. Тагын дүрт елы калган.

– Мәктәптә укытучылар җитмәгәч, чакырганнар иде. Безнең мәктәптә 50дән артык укучы белем ала. Сыйныфларда – 3, 5, 7 бала. Беренче елны авыр булды. Үзеңнең сәләтеңне, балаларны ратуыңны күрсәтә белергә кирәк. Укыту гына түгел, тәрбия бирүнең нечкәлекләре дә бар. Укытучы хезмәте авыр, әмма тырышсаң, эшләргә була, – диде оптимистик рухлы Рәмис.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәмис Газизовка: «Ни өчен яшь укытучылар мәктәптә озак эшләми?» – дигән сорауны да бирдек. Егет фикеренчә, бер ел эшләп карагач, укытучы бу һөнәрне дөрес сайлавы яки сайламавын аңлый. Ялгыш килүчеләр китәргә мәҗбүр. «Акча мәсьәләсе дә үзенекен итә. Бүген авылда яшь укытучылар 20 мең сум хезмәт хакы ала. Авыл өчен әйбәт инде бу, әмма шәһәр өчен бик аз. 30 мең сум булса, яхшы. Авылда калачакмын, дип кырт кисеп әйтә алмыйм, әмма юлымны шушы юнәлештә дәвам иттерәчәкмен», – диде ул.

Яшел Үзән районының Норлат авылы кызы Рәнилә Насыйбуллина да үз язмышын укытучылык белән бәйләгән. Ул да Казан мәктәбендә ярты ел сыналырга өлгергән икән. Быел Яшел Үзәндәге 16 нчы мәктәпкә эшкә кайтачак. «Яшьләр мәктәптә калсын өчен, аларны кызыксындыру чаралары булдырырга кирәк. Әйтик, быел кыш көне безгә премия бирделәр. Акчамы, ниндидер мактау сүзләреме... Укытучыларны канатландырып җибәрәчәк бу. Балалар белән эшләү – бер, әмма әти-әниләр белән– икенче әйбер. Теләсә кайсы проблеманы да хәл итеп була дип уйлыйм», – ди ул.

Тантанада катнашкан Татарстанда Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурскаядан мәгарифтәге кыенлыклар турында сораштык.

– Безгә җәберләү (буллинг) очраклары буенча да мөрәҗәгатьләр килә. Узган елда андый хәлләр булды. Без Рособрнадзор вәкилләре белән мәктәпләргә барып, укытучылар, мәктәп җитәкчеләре, психологлар белән аралашабыз, проблемаларны ачыклыйбыз. Буллинг зурлардан башлана һәм алар ярдәме белән хәл ителә, – диде ул.

Заманасында үзе дә мәгариф системасында эшләгән Сәрия Сабурскаяга, сәхнәгә күтәрелгәч: «Киләчәк укытучысы нинди булырга тиеш?» – дигән сорауны да бирделәр.

– Монда килгәндә, бер хәлне искә төшердем. Ул вакытта мәктәп Карпов исемен йөртми иде әле. (Карпов – «Майский» совхозының беренче директоры.) Миңа иртүк мәктәп директоры: «Безнең мәктәптә – гадәттән тыш хәл. Укучылар кичен мәктәпкә килеп, укытучылар бүлмәсе каршында барлык журналларны җыеп яндырганнар», – дип шалтырата. Май ае иде ул. Коточкыч хәл. Хәзер инде балаларның белеменә ничек бәя бирик? Ул вакытта электрон журнал, көндәлекләр юк. Бу – кичәге мәктәп. Хәзер мәгариф системасы башка, технологияләр дә, матди ягы да үзгәрә. Без хәтта һәр укытучының ноутбугы, һәр мәктәптә интерактив такта булыр дип хыяллана да алмый идек. Хәзер авыл һәм шәһәр мәктәпләрендә дә мөмкинлекләр тудырылган, – дип хатирәләрен бүлеште Сәрия Сабурская.

Яшьләргә фатыйхасын биреп: «Сез бүгеннән үк балачакның кадерле булуын аңлагыз. Һәр бала белән уртак тел таба белергә тиешсез, аларның һәркайсына мәктәпне, сыйныфны яратырга өйрәтегез. Әти-әниләрнең сезгә ышаныч белдерүе дә бик мөһим. Менә шул вакытта белем дә, тәрбия дә яхшы булачак», – диде ул.

Көзге кешбэк

Туристларга Россия буенча көзге сәфәрләр дә арзангарак төшәчәк. Ростуризм башлыгы Зарина Догузова әйтүенчә, 25 августтан 10 сентябрьгә кадәр көзге кешбэк программасы буенча турлар сатылачак. Ә инде сәфәргә илебезнең теләсә кайсы төбәгенә 1 октябрьдән ел азагына кадәр юл тотып булачак. Теплоходларда исә кешбэклы сәяхәт 1 сентябрьдән навигация тәмамланганчы дәвам итәчәк. Шартлары элеккечә үк: юллама бәясенең 20 проценты (күп дигәндә – 20 мең сум) кире кайтарыла. Шул ук вакытта, Догузова искәртеп үткәнчә, бер яңалык та бар. Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча, Ерак Көнчыгышка сәфәр кылучыларга, программада катнашучы кунакханәне броньлау очрагында, 40 мең сум кире кайтарылачак.

Исемлектә – 22 район

Татарстанның тагын өч авылында Африка чумасы табылган. Бу юлы Югары Ослан һәм Спас районнарында чир ачыкланган. Шулай итеп, карантин игълан ителгән районнар инде 22гә җиткән. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов өч хуҗалыкка карантин кертү буенча тиешле указга кул куйган. Югары Ослан районы Килди авылында «Пашков Сергей Игоревич» фермер хуҗалыгына, Спас районы «Куйбышев» ау хуҗалыгы территориясенең бер өлешенә һәм Спас районы Коминтерн бистәсе Бураково авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыкка карантин кертелгән.

Документ нигезендә, чир табылган урынга кереп йөрү (ветеринария хезмәткәрләреннән тыш), шулай ук анда терлек чалу, ит һәм терлек азыгы сату тыела. Моннан тыш чирне юкка чыгаруга җәлеп ителмәгән транспорт та кертелми.

Чир табылган урыннан 5 чакрым радиуста урнашкан территория хәтәр территория булып санала. Бирегә терлек кертү, ит, терлек азыгы әзерләү, сату һ.б. тыела.

«Кара исемлек»кә Аксубай, Алексеевск, Әлки, Апас, Арча, Әтнә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Спас, Тәтеш, Теләче, Чистай районнары эләккән.

Җиңү диктанты

Татарстанда «Җиңү диктанты – 2022» үткәрү өчен 150дән артыграк мәйданчык оештырылачак. Диктант язучылар «Бердәм Россия»нең «Диктант Победы – 2022» халыкара акциясе сайтында теркәлә. Алар республиканың зур предприятиеләре һәм вузларында үзләренең белемнәрен сынаячак.

«Бердәм Россия»нең «Тарихи хәтер» проекты координаторы, Татарстан Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова әйтүенчә, диктантны, гадәттәгечә, хәрби частьларда, хәрби уку йортлары, көч ведомстволарында: Казан һәм Алабуга Суворов училищелары, Казан танк училищесы, Казан юридик институты, Янгынга каршы федераль хезмәтнең укыту-өйрәтү үзәге, Хәрби комиссариатта язачаклар. Шулай ук Казан дары заводы, «Татхимфармпрепараты», «Серго исемендәге завод» кебек зур предприятиеләр дә акцияне хуплаган.

Диктантта (тест биремнәрен үтәү рәвешендә) катнашу илебез тарихы буенча үз белемнәреңне тикшереп карау, ата-бабаларыбызның батырлыклары турында ниндидер яңа мәгълүматлар белү мөмкинлеге ача. Исегезгә төшерәбез: «Бердәм Россия»нең «Җиңү диктанты» халыкара акциясе 3 сентябрьдә уздырылачак.

Сәламәтлек

Онытырга ярамый

РОСПОТРЕБНАДЗОР ПРИВИВКАЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕН ИСКӘРТТЕ

Балачакта прививка ясатулар юкка түгел. Ул озак еллар иммунитетны куәтләп торырга ярдәм итә. Тик вакыт узгач, аның да тәэсире кими. Димәк, яшь барган саен, кабат вакцина ясату зарур. Роспотребнадзор шул хакта белешмә әзерләгән.

Асылда, сүз Илкүләм прививкалар календарена караган прививкалар турында бара. Әйтик, һәр 10 ел саен өлкәннәргә дифтерия, столбняк инфекцияләреннән вакцинация һәм ревакцинация ясату каралган. Болар куркыныч инфекцияләр санала.

Шулай ук кызамык, кызылча чирләреннән дә сакланырга кирәк. Алар – баш миенә зыян китерә торган чирләр. Үлемгә дә китерергә мөмкин.

Пневмококктан һәм грипптан прививка ясату турында барыбыз да белә инде. Аны бөтен кешегә дә ясатырга киңәш итәләр. Аеруча хроник авырулары булган, 60 яшьтән өлкәнрәкләргә үз сәламәтлеген шул рәвешле дә кайгырту сорала. Роспотребднадзор белешмәсендә әйтелгәнчә, вакцина ясату өчен иң кулай вакыт – көзен.

Җәйге чорда исә менингококк инфекциясе һәм А гепатиты авыруыннан прививка кадату турында онытмаска кирәк. Моны бигрәк тә сәяхәт, актив ял һәм аралашу ярата торган кешеләр исеннән чыгармасын иде. Менингит – бик куркыныч чир. Ул, тиз арада үсеш алып, үлемгә китерергә мөмкин.

Моңа өстәп, В гепатитыннан прививка ясату да зыян итмәс. Билгеле булганча, бу чир бавыр яман шеше һәм цирроз да китереп чыгара ала.

minzdrav.tatarstan.ru

Талпан энцефалиты турында да онытырга ярамый. Роспотребнадзор белешмәсендә язылганча, Россиядә талпаннар күпләп таралган төбәкләр шактый. Шуңа күрә урманда яки паркта йөреп кенә түгел, бакчада эшләгәндә дә инфекциягә юлыгырга мөмкин. Саклык чарасын алдан күрергә кирәк.

Медицина бер урында гына таптанып тормый. Галимнәр миллионлаган кешенең сәламәтлеген саклап калырдай даруларны да уйлап табарга өйрәнде. Шулай да прививкаларның файдасы турында да онытырга кирәкми. Роспотребнадзор белгечләре искәрткәнчә, вакцина ясату йөрәк өянәге, артрит, яман шеш авыруларының кайбер формалары үсешен булдырмый калырга һәм кешенең сәламәтлеген, тормыш сыйфатын имин дәрәҗәдә тотарга булыша.

Сүзгә-сүз

Сергей МИТИН, Федерация Советының Аграр азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитеты рәисе беренче урынбасары:

Автоматтан су белән сәүдә итүне үстерү безгә генә хас әйбер түгел. Бөтен дөньяда шулай. Экология өчен бик мөһим ул, чөнки пластик савытлар экономияләнә. Галимнәр исәпләп чыгарганча, бер водомат бер ел эчендә пластик шешә җитештерүне 30 мең данәгә киметү мөмкинлеге бирә. Әмма, минемчә, автоматларда су сатуга контроль көчәйтелергә һәм бу эш дәүләт органнары карамагында булырга тиеш.

(«Парламентская газета»)

РОССИЯ ХАЛКЫ ДАРУГА КҮПМЕ АКЧА САРЫФ ИТӘ?

«Росгосстрах» һәм «Россгострах жизнь» компанияләре, уртак сораштыру оештырып, ил халкыннан шул хакта белешкән.

ДАРУГА КҮПМЕ АКЧА ТОТЫЛА? (Ел дәвамында)

10 мең сумга кадәр	>>	55%
10–30 мең сум аралыгында	>>	25%
Зур сумма	>>	20%

Бәяләр төшә

Татарстанда яшелчә, җиләк-җимеш һәм кайбер азык-төлек бәяләре кимү күзәтелә. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, 1–8 август чорында иң элек кишер күпкә арзанайган (12 процентка). Бу чорда аның бәясе 52 сумнан 46 сумга калган. Кыяр – 7 процентка (74 сумнан 69 сумга кадәр төшкән), кәбестә һәм бәрәңге хакы 6 процентка кимегән (25 сум һәм 36 сум).

Банан һәм помидор бәяләре 4 процентка төшкән (79 сум һәм 89 сум). Алма 2 процентка арзанаеп, килосы 113 сумга калган. Моннан тыш карабодай һәм дөге хакы 1 процентка кимегән (110 сум һәм 98 сум).

vk.com

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тарихны бизәү – киләчәккә кизәнү

«Үткәнне контрольдә тоткан киләчәкне дә кулыннан ычкындырмый». Бу сүзләр Джордж Оруэллның данлыклы антиутопиясендәге каты тоталитар режим үз иткән шигарь генә дисәгез, ялгышасыз. Формула реаль тормышта, чынбарлыкта да яши һәм кулланыла. Дәүләт идеологиясеннән ваз кичмәгән дәүләтләрдә сәясәтчеләр әле дә үткәнне боргаларга, аны бизәргә яраталар. Идеология дип аталган исерткеч тәгълиматның тарихка ышыкланып ясалганы массалар өчен үтемлерәк чөнки. Тарих бизәлгән җәһәттә дә. Андый алым эшкә җигелгәндә үткәннәр һәрчак данлы вә шанлы. Сугышлар гел җиңүләрдән генә торган. Бабайлар да – кайсы дәверне генә алма, тиңдәшсез батырлар. Хәзерге буын да алар кебек булырга, ил дигәндә, җанын да, малын да кызганмаска тиеш. Күп тарафларда кулланылучы мондый стандарт аңлатма-өндәүләргә соңрак, гадәттә, теге яки бу илнең, халыкның бөеклеге хакындагы тәкбирләр дә китереп кушыла.

Тарихи хәтер, аның дөреслеге дигәндә, кайберәүләр үткәнне җиңелчә матурлап кына калмый, хәтсез очракларда артык мавыгып китә һәм чынбарлык белән уртаклыгы булмаган, яисә аз булган вакыйгаларны, ялган һәм ярым ялган геройларны тудырып куя. Мәсәлән, Куликово сугышы. Карамзинга чаклы дүрт ярым гасыр буе ул сугышны искә алган кеше дә булмый, «монголо-татарское иго» төшенчәсе дә бөтенләй кулланылмый. Куликово кырының да кайдалыгын һичкем белми. Кечкенә бәрелешне мәшһүр җиңү итеп күрсәтү XIX гасырның беренче чирегеннән соң башлана. XX гасыр урталарында исә Дмитрий Донскойга бер-бер артлы һәйкәлләр калка, сугышка багышланган рәсем-полотнолар ярала, кинолар төшерелә. Тик менә археологларның гына, күпме генә казынсалар да, шушы көннәргәчә ул кырда ук, сөңге очлары да, кеше сөякләре дә таба алганы юк. Хәер, анысының идеологларга кирәге дә юк. Бөек җиңү турында миф тудырылган, һәйкәлләр куелган, дәреслекләргә кертелгән…

Гади халык шуның өчен дә гади: геройларның, вакыйгаларның кайсы чын, кайсы өреп кабартылган – аралап тормый, тулысы белән «йотып» бара. Азлар гына бөртекне кибәктән аера. «Мин тарихка гомумән псевдофән дип карыйм». КФУда төгәл фәннәр укытучы галим, фикерен сорагач, шулайрак җавап биргән иде. «Кызыллар килгәч – кызыл, аклар килгәч – ак тарих».

Бүген без яшәгән илдә, Конституциянең 13 маддәсе нигезендә, дәүләт идеологиясе тыелган. Әмма үткәнне яхшыртуга, ул эшне башкарганда бер чиктән икенчесенә ташлануга тыю юк. Россиянең элекке мәдәният министры Владимир Мединскийның, килеп, вазыйфаларына керешер-керешмәстән, революционерлар исеме белән бәйле урамнарны башкача атап чыгу тәкъдиме кертүе, шуны гамәлгә куюы хәтердә. Ягъни узган гасырның туксанынчы елларында ук башланган мәрәкәнең яңа түрә килүгә өстәмә тизләнеш алуы. Нәтиҗәдә, язуларынча, дистәдән артык шәһәрдә бүген, мәсәлән, Желябов һәм Перовская урамнары юк. Алар хәзер башкача атала. «Кызыл»лар чорында герой саналган «Народная воля» оешмасы әгъзалары, социалистик идеядән ваз кичүгә, бомба шартлатучыларга, террорчыларга әверелде. Татар башкаласында икенче бер народоволец – Степан Халтурин исемен йөрткән урам бар. Без аңа кагылмадык һәм дөрес эшләдек. Исемнәре революцияләр, Совет власте урнаштыру белән бәйле Урицкий, Воровский, Волков, Ершов, Бауман урамнары да шул килеш калды. «Ак»лар тарафыннан килгән күп төрле тәкъдимнәргә дә карамастан, элекке Комлев урамын исәпләмәгәндә, исем алыштыру дигән матавык олы шаукымга әйләнмәде кебек.

Идеология дип, ярымтоннарны күрмичә, акны – карага, караны акка алыштыру ул – ни генә димә, радикаллык. Ул хәл тарихны да радикаллаштыра. Гомумән дә, хакимиятнең, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, үз файдасын эзләп, тарихны сәяси инструмент итүендә бер яхшылык та юк. Совет чорында кара саналган бар нәрсә дә бүген ак була алмый. Шул исәптән самодержавие дә. Шул ук Халтурин, Желябов, Перовская, алардан да алда «Земля и воля» әгъзалары кесәләрен калынайту өчен яшерен оешма төземәгән. Ә илне, андагы тәртипләрне үзгәртү, яхшырак итү өчен тырышкан. Ул чор нәрсә белән үзенчәлекле дигәндә, крестьян, крепостнойлыктан азат ителеп тә, җиргә хуҗа була алмый. Илдә бер-бер артлы крестьян фетнәләре кабына. Алар патша хөкүмәте тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырыла. Җәза отрядлары илдә чып-чын террор оештыра. Шуңа өстәп, канга батырып бастырылган поляк восстаниесе. Себергә сөргенгә аткарылган меңәрләгән поляк кешеләре, аларны да асу һәм кисү. Император Александр IIне «асучы» («Александр-вешатель») дип атый башлаган вакытлар.

Нәкъ шул чорда рәхимсезлеккә, гаделсезлеккә җавап рәвешендә «Җир һәм ирек», соңрак «Халык иреге» кебек оешмалар ярала. Революционерлар, яшерен оешма төзегәндә, министрларга, югары түрәләргә бомба ату хакында башларына да китерми. Алар куйган таләпләр без бер гасырдан артык вакыт үткәч – 1991 елда куйганнарга тәңгәл. Сүз һәм матбугат иреге, идарә органнарында халык вәкилләре булу, барлык катлауларның да закон каршында тигезлеге. Кыскасы, гомумдемократик таләпләр. Тик шул ук народоволецларны ишетүче булмый. Башка юллар калмагач, гаҗизлектән дип әйтик, алар кулларына бомба ала – дәүләт оештырган канлы террорга террор белән җавап бирә башлый. Бүген төгәл мәгълүм: «Народная воля» кулыннан барысы 7 кеше үлә. Ә инде патша самодержавиесенең репрессив органнары теге дөньяга озатканнар йөзләр белән исәпләнә. Демократик ирекләрне илгә, 30 елга соңга калып булса да, барыбер бирергә туры килә. Николай II 1905 елда кул куйган ул документның «17 октябрь манифесты» дип аталганын беләбез…

Кемдер, бәлки, әйтер: йөз, өч йөз, мең ел элек булган вакыйгаларга мөнәсәбәт нинди булса да ярамыймыни, дияр. Юк шул, алай түгел. Үткәнне даими боргалап тору тарихи хәтернең юылуына, тарихка ышанмауга, аны псевдофән дип атауга китерә. Ул гынамы, тарихи ялганны абайлаган, белгән кешенең хәтта ки теге яки бу халык вәкиле булып яшәүдән күңеле кайтырга да мөмкин. Чөнки ялган бар икән, ул, кагыйдә буларак, тарихка гына кагылмый. Бәндәнең, барысына кул селтәп, башка – адәм рәтле саналган илгә китәсе килә башлый. Җыеп әйткәндә, озакка сузылган тарихи ялган кешене үз үткәненә битараф итә. Ә инде үткәнен белмәгән, аның белән кызыксынмаган халыкның гына түгел, ул халык төзегән дәүләтнең дә киләчәге шактый шикле. Үткәнне түгел, бүгенгебезне яхшыртсак иде.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Геройлары Иван Додосов һәм Раил Габдрахманов белән очрашты. Исегезгә төшереп үтик: Татарстан егетләре Украинадагы махсус операциядә катнаша. Хәрбиләр анда күрсәткән батырлыклары өчен Россия Герое исеменә лаек булдылар. Габдрахманов та, Додосов та – Казан танк училищесы шәкертләре. Рөстәм Миңнеханов аларга хезмәт карьерасында үсеш һәм уңышлар теләде.

ЮЛ ДА, КҮПЕР ДӘ ИСӘПТӘ

Юлларга киртәләр куелачак, Казандагы «Миллениум» күпере төзекләндереләчәк… Яңа төзелүче Вознесение тракты да вакытында кулланылышка тапшырылачак, дип ышандыралар. Татарстанда юл эшләре барышына багышланган матбугат очрашуында шул хакта сөйләштеләр.

Быел Татарстанда юл программаларын тормышка ашыру өчен 60,5 миллиард сумнан артык акча сарыф ителәчәк. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 10 процентка күбрәк. Әлеге акчага республикада 52,5 чакрым юл төзеп, 610 чакрым юлны төзекләндерергә җыеналар. Бүген бу эшләрнең 44,8 проценты башкарылган инде. Моннан тыш быел Татарстанда 45 мәктәп маршруты белән 22 медицина оешмасына, 26 спорт һәм туризм объектына илтүче юлны да төзекләндерергә җыеналар. Тоткарлыклар килеп чыкмаса, 2024 елда Казанда Вознесение тракты да ачылачак.

– Киләсе ел өчен финансларның кайсы чыганактан бүлеп биреләчәге әлегә билгесез. Инфраструктур бюджет кредиты акчасын җәлеп итү күздә тотыла. Акча вакытында бүлеп бирелсә, бу объект буенча юлны 2024 елда ук ачып булачак, – ди министр урынбасары.

Татарстан транспорт министры урынбасары Артём Чукин сүзләренә караганда, бүген Вознесение трактының беренче этабында планлаштырылган эшләрнең 67 проценты тәмамланган. Бу проектны тормышка ашыру өчен барлыгы 13,4 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

Чукин сүзләренә караганда, яңа төзелүче М12 Мәскәү – Казан трассасында эшләр план буенча бара. «Күпер ике яклап ныгытыла. Җир эшләре, коммуникацияләр уздыру да планлы рәвештә башкарыла», – ди министр урынбасары.

Хәтерләсәгез, күптән түгел Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин, М12 трассасы ил тарихында иң тиз төзелгән автомагистраль булачак, дип ышандырган иде. «Бар да без уйлаганча барса, Россия тарихында иң тиз төзелгән автомагистраль булачак бу. 2,5 елда 3830 чакрым юл төзеләчәк», – диде ул үзенең бер чыгышында. Яңа М12 трассасы буйлап Мәскәүдән Казанга 6,5 сәгать эчендә кайтып булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Киләсе елга Казандагы «Миллениум» күперен дә төзекләндерергә җыеналар. Борисоглебск торак массивындагы күпер дә яңартылачак. «Миллениум» күперендә су кайтару буенча эшләр башкарылачак. Күперләрнең иң «авырткан» урыны инде бу», – ди «Главтатдортранс» оешмасы җитәкчесенең беренче урынбасары Александр Куканов.

Сүз уңаеннан, бер ел эчендә республика юлларында үлем-китем очраклары арткан. Артём Чукин сүзләренә караганда, былелның гыйнвар – июль аралыгында республика юлларында 1,7 мең юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 157 кешенең гомере өзелгән. Бу алдагы елның шушы чоры белән чагыштырганда 9 очракка күбрәк.

Юл фаҗигаләрен киметү максатыннан Чаллы – Зәй – Әлмәт юлында киртәләр куя башлаганнар. Быел бире дә узган ел башланган төзекләндерү эшләре дә тәмамланып килә.

– Бу юлда тулысынча диярлек киртәләр куелачак. 27 чакрымлык киртәнең 22 чакрымы куелды инде. Бу эшне 1 сентябрьгә тулысынча тәмамларга уйлыйбыз. Бу юлда каршы як полосаларга чыгуларга киртә куячак. Шул рәвешле юл фаҗигаләре саны да кимер дип өметләнәбез, – ди Артем Чукин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

һӘРБЕР КИРПЕЧЕ – СЕЗНЕҢ КУЛ КӨЧЕ

Иртәгә – Төзүчеләр көне. Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин төзелеш тармагында эшләүчеләрне, ветераннарны һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Нәтиҗәсен һәрбер кеше күреп-сизеп торган һөнәрләр күп түгел, – диелә котлауда. – Өй, балалар бакчасы, мәктәп, хастаханә, парк яки сквер – боларның барысы да кешенең яшәеше өчен бик кирәк әйберләр. Ә аларның һәркайсы – сезнең хезмәт җимеше.

Төзүчеләр – ил үсешендә турыдан-туры катнашучылар да әле: нәкъ менә сез аның төзеклеген тәэмин итәсез, киләчәк буыннарның иминлеге нигезен булдырасыз, Россиянең халыкара икътисади мәйданда тоткан урынын, мөстәкыйльлеген һәм иминлеген ныгытуга ярдәм итәсез. Киң колачлы инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру, яңа сәнәгать производстволарын эшләтеп җибәрү сездән башка гына булмый.

Сезнең хезмәт җиңелләрдән түгел. Бөтен көчне биреп эшләүне, даими үсешкә һәм камиллеккә омтылуны таләп итә ул. Төзелеш, гадәттә, икътисадның башка секторларын үстерүгә этәргеч булып тора. Төзелештәге һәрбер эш урыны башка тармакларда кимендә 3–4 эш урыны бирә.

Кадерле дуслар! Бүген илебез уникаль шартларда яши. Әйе, чикләүләр эшебезне катлауландыра. Әмма алар инде илебезнең төзелеш технологияләрен үстерүгә, заманча төзелеш материаллары производстволарын булдыру, яңа чишелешләрне уйлап табуга этәрәчәк. Белемегез, яңаны булдыруга, иҗатка омтылышыгыз иң кыю хыялларыгызны гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирәчәк!

Сезне чын йөрәктән һөнәри бәйрәмегез – Төзүчеләр көне белән котлыйм! Сезгә нык сәламәтлек, гаилә бәхете, яңа үрләргә ирешүегезне телим!»

Ялны яраталар, чүпне юк!

Әйләнә-тирә

Кичә Казанда Идел ярларын чистарттылар. Өмә Бишбалта бистәсендә узды. Анда 1 меңнән артык кеше катнашты. Татарстаннан тыш, шулай ук бу чарага өч төбәк – Карачай-Черкес, Ингушетия һәм Төньяк Осетия – Алания экоактивистлары да кушылды Республикада мондый чаралар еш оештырыла. Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы вәкилләре сүзләренә караганда, яр буйларын җыештыру эшләре даими үткәрелә.

– Шулай без Лаеш һәм Мамадыш районнарында икешәр яр буен чүп-чардан арындырдык. Шулай Чаллыда Мәләкәс елгасын чистарту проектына старт бирдек, – ди Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский. –Яр буйларын чистарту һәм экологик акцияләр саны буенча Татарстан – лидерлар рәтендә. Узган ел сулыкларны чистарту буенча илнең барлык төбәкләре арасында беренче урынны яуладык. Бездә үткән чарада 10 мең чакрым озынлыктагы яр буе полосасы чистартылды, ә өмәгә 276 меңнән артык кеше кушылды.

Соңгы елларда экологиягә караш бөтенләй башкача, ул уңай якка үзгәрә. Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков бер очрашуда аеруча яшьләрнең тирә-якка сакчыл каравына шатлануын сөйләгән иде. Егор Тарнавский да шул ук фикердә.

– Елдан-ел без уздырган чараларда катнашучылар саны арта бара. Мондый акцияләр экологик үзаңны, культураны тәрбияләп, республикабызның бай табигатен саклап калырга мөмкинлек бирә, – ди ул.

Идел яр буен чистартучы Рус географик җәмгыяте вәкилләре дә республика халкына экологиягә мөнәсәбәте өчен рәхмәтле.

– Бүген без еш кына сулыклардан балык тоту кирәк-яраклары, кармаклар, консерв банкалары, ятьмәләр табабыз. Болар бит Иделдә су коенучы һәм балык тотучылар өчен генә түгел, балыклар һәм суда яшәүче бар хайваннар өчен дә куркыныч, – ди драйвер Станислав Андронов.

Иделдән чыккан чүп-чарны шунда ук төрләргә дә бүлделәр. Пыяла, металл, кәгазьләрне аерым капчыкларга салдылар. Калдыклар махсус полигонга җибәреләчәк. Әле эшләр моның белән генә бетми. Татарстанның Рус географик җәмгыятенең төбәк бүлеге рәисе урынбасары Андрей Агарков сүзләренә караганда, төп бурычлары – Идел елгасы ярларын чистартып бетерү.

– Бишбалта бистәсендә кешеләр ял итәргә ярата да, артларыннан чүпләрен җыярга яратмыйлар. Волонтерлар алдында Идел елгасы ярларын чистарту бурычы тора. Ә иң мөһиме – азрак пычратсак иде. Монда ял итүчеләр дә белеп торсыннар: алар ташламаган чүптән сулыкларга күпме дәва булачак, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТУЗАННЫҢ БӨРТЕГЕ ДӘ ЮК

Татарстанның Архив эшләре буенча дәүләт комитеты Лаеш районының Столбище бистәсендә яңа төзелгән архив бинасына журналистларны җыйды. Хәзер инде монда эшләүчеләр турында да, йомышы төшеп килүчеләр турында да, архив тузанын иснәп утыралар, дип һич кенә дә әйтеп булмый. Киресенчә, тузанның бөртеге дә юк.

210 мең тартмага тутырылган документларны архивның яңа бинасына 35 көн эчендә күчергәннәр. Моннан тыш 40 мең аудиодокумент, аларны реставрацияләү һәм күчермәләр алу өчен җиһазлар да бинада үз урынын алган. Яхшы дип мактанып кына калмадылар, дәлилләр ышандырырлык булды. Журналистлар, архивчылар оештырган мастер-классларда катнашып, үзләре дә китап битләрен «төзекләндереп» карады.

Россиянең төрле төбәкләрендә барлыгы 8 шундый махсуслашкан архив бинасы төзү каралган булган. Әмма бу хыял әлегә Татарстанда гына тормышка ашкан. Әйтергә кирәк, проект буенча әлеге бина Идел буе округы төбәкләре архивларын үз эченә алырга тиеш булган. Соңыннан ул, Татарстан Республикасының архив эшләре буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова әйтүенчә, Президент Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән республиканыкы гына булып калган.

Сан

Яңа архив биналарының гомуми мәйданы – **23697,2** кв. м, архивны саклау мәйданы **14648,48** кв. метрга җитә. Элекке биналарның гомуми мәйданы – **16096,3** кв. м, архивны саклау мәйданы **9861** кв. м була.

Архив хезмәткәрләре сүзенә ышансак, бина искиткеч югары дәрәҗәдә, уйланып төзелгән. Хәтта төртеп күрсәтерлек җитешсезлекләре дә юк, диләр. Дөрес, йөрү өчен бик ерак һәм уңайсыз, дип зарланучылар бар икән үзе. Бу проблеманы да хәл итәргә җыеналар. Казан тимер юл вокзалыннан аэропортка йөрүче электричка өчен нәкъ менә архив бинасы янында тукталыш булыр дип көтелә. Бу хакта каләм ияләренә комитет җитәкчесе урынбасары Илнур Шәрипов җиткерде. «Узган атнада монда Горький тимер юлы җитәкчесе белән Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры булып китте. Сөйләшү шул тукталыш хакында булды», – диде ул. Моңа өстәп, Гөлнара Габдрахманова архив бинасы янында киләсе елның яз айларында автобус тукталышы булачагын да әйтте.

Әйтергә кирәк, архивка эше төшкән халыкны сөендерергә дә мөмкин. Халык белән эшләү бүлеге әлегә элеккечә 8 Март урамында урнашкан архив бинасында кала.

– Минемчә, Декабристлар урамының 4 нче йортында урнашкан филиал да калыр, – ди комитет җитәкчесе. – Чөнки хакимият органнарына документларны анда китерергә уңайлырак. Өстәвенә без ул бинаны 2018 елда гына төзегән идек. Анда документларны тузаннан арындыру, цифрлаштыру өчен җиһазлар да бар. Бердәм мәгълүмат системасына кертү эшләре дә башкарыла. Бу исә – бик катлаулы процесс. Икенче төрле әйтсәк, бу бинада документлар кабул ителә һәм беренчел эшкәртелә. Аннан соң гына тартмаларга тутырылып, дәүләт архивына җибәрелә. Болай эшләү бернинди кыенлыклар да тудырмый, тикшеренүчеләр өчен архив ишекләре һәрвакыт ачык. Онлайн режимда эшләүне дә кире какмыйбыз. Хәтта чит илләрдән дә мөрәҗәгать итүчеләр бар. Дөресен генә әйткәндә, без барлык документларны да цифрлаштыру юлына аяк бастык инде. Кәгазьдәге язулар югала, искерә, аннан барыбер гел файдаланып булмаячак.



«Татар-информ» / Михаил Захаров

Киләчәктә дә үзгәрешләр булмый калмас, ди архивчылар. «Без бер бина белән генә чикләнергә уйламыйбыз. Монда Архив шәһәрчеге булачак. Хөкүмәт безгә шундый саллы ярдәм күрсәтә икән, димәк, архивны саклау – бик кирәкле гамәл», – диде бу җәһәттән Гөлнара Габдрахманова.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

МИЛЛӘТ ҺӘМ ӘХЛАК САГЫНДА

«БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ» БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ БҮЛӘКЛӘНДЕ

Нәтиҗә

«ВТ» редакциясендә кабат кунаклар! Кунакларның да ниндиләре! Редакциягә газета һәм Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте белән берлектә оештырган «Безнең авыл имамы» бәйгесенең җиңүчеләрен чакырдык. Бәйге Идел буе Болгар дәүләтендә ислам диненен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган иде.

Дин, тел, милләт турында күпме генә сөйләсәк тә, урынлы. Авылларыбызда исә бу мөһим вазыйфа имамнарыбыз җилкәсенә төшә. Үсеп килүче буынны хак кыйммәтләрдә тәрбияләү, сала халкын иман, әдәп юлыннан алып бару да – алар бурычы.

Бәйгебездә җиңү яулаган авторларыбыз да нәкъ шундый кешеләр турында язган иде. Хатлары да, язма нигезендәге геройлары да сокланырлык, сокландырырлык булды. Моны газетаны даими укып баручылар да инкарь итмәс. Конкурска килгән язмалар барысы да «ВТ» битләрендә урын тапты.

Баш мөхәррир Гөлнара Сабирова, кунакларны тәбрикләп, рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Бәйгегә 50дән артык эш кабул ителде. Башка бәйгеләребез белән чагыштырып караганда аз сан булса да, тема үзенчәлеген исәпкә алсак, бик яхшы күрсәткеч дип саныйм. Әле яңа гына булып узган Бөтендөнья татар конгрессы съездында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та, мәчетләр дин өйрәтү үзәкләре булудан тыш, тел өйрәтү урыны да булырга тиеш, дип ассызыклады. Безнең газетабыз да һәрвакыт тел сагында булды. Бу темага алынуыбыз да юкка түгел, – диде ул. – Авылның да, телнең дә төп сакчысының берсе – дин. Диния нәзарәтенең дә соңгы елларда эшчәнлегенең бер юнәлеше – мәчетләрдә тел өйрәтү. Бәйгегә килгән язмаларда да шул хакта укыдык. Имамнарыбыз авылларда бу юнәлештә шактый эш башкара. Язмаларыгызны сөенеп укыдык. Көчле имамнарыбыз бар, алар авыл үсешенә зур өлеш кертә. Бөтен авылларда да андый хәл була алмыйдыр шул. Әмма үрнәкләрне күрсәтәсебез килде. Башка авыллар да, шуларга карап соклансын һәм моңа омтылсын иде.

Баш мөхәррир әйтүенчә, жюри вәкилләренә җиңүчеләрне сайлау җиңелләрдән булмаган. Өстәмә премия һәм рәхмәт хатлары да булдырылган. Бу инде язмаларның чыннан да көчле һәм сыйфатлы булуын тагын бер кат дәлилли.

Шунысы да куанычлы: бәйге барышында бер үк имамнар турында берничә кешедән хатлар кабул ителгән. Моңа кадәр безнең бәйгеләребезгә игътибар итми калган районнарның да кушылуы сөендерә.

Бәйге җиңүчеләрен котларга Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов та килгән иде. Форсаттан файдаланып, ул газетага да дини юнәлештә алып барган эше өчен рәхмәтен җиткерде.

– Имам – олуг вазыйфа. Имам сүзенең гарәп телендәге мәгънәсенә карасак, ул – алда басып торучы дигәнне аңлата. Чынлап та шулай. Намазда да, тормышта да, мөнәсәбәттә дә. Аллаһның биргәненә шөкер, республикабызның авылларында да тырыш, әдәпле, белемле имамнарыбыз шактый. Алар динебез, милләтебез хакына олуг эшләр алып бара. Конкурс җиңүчеләренә дә имамнарның эшләренә игътибар итеп, аларны хөрмәтләгәнегез өчен рәхмәт әйтәсе килә, – диде хәзрәт. – Бердәм һәм бергә булганда динебезне саклый алабыз.

Мәхәллә эшен алып бару – җаваплы да, катлаулы да. Илфар хәзрәт искәрткәнчә, җирле имамнар үз хәлләрен үзләре генә белә. «Авыл халкы да, авылларда инде яшәмәүчеләр дә мәхәлләгә даими ярдәм итеп торсын иде. Сүз матди ярдәм турында гына бармый. Хәл-әхвәл сорашып, мәчетләргә килеп китсәк тә, ничек саваплы булыр», – диде мөфти урынбасары.

Җиңүче авторларыбыз үзләре нинди хисләр кичерә соң?

Ләйлә Хәйруллина – булачак коллегабыз икән. Шәле кызы Россия ислам университетында журналистика юнәлеше буенча белем ала. Ислам тематикасына багышланган матур язмалары белән алга таба да сөендерергә вәгъдә бирде җиңүчебез.

Яңа Чишмәдән Мәймүнә Хәйретдинова да хис-кичерешләрен тыя алмый. Зирекле дигән зур, төзек, саф татар авылыннан килгән ул безгә. Коръәнне дә укый белә икән. Догалардан җан тынычлыгы алам, ди. Авылларындагы дини тәрбиянең никадәр көчле булуына язмасыннан укып кына түгел, үз теле белән сөйләвен ишетеп тә таң калдык.

– Моннан 30–40 еллар элек авылларда хәлләр мөшкел иде бит. Кызлар белән кызлар сугыша торган заманнар да булды. Әхлакны кайтарырга кирәк иде… Шөкер, хәзер дини тәрбия бар, безнең мәчеттә укулар атна буе бара. Мәктәп балалары анда йөгерә-йөгерә бара. Кызлар аерым, малайлар аерым укый. Хәзрәт барысына да өйрәтә. Яшьләр, өлкәннәр төркемнәре бар, – ди Мәймүнә ханым. – Язмамны бәяләп, шушы матур бәйрәмгә чакыруыгыз өчен рәхмәт. Мин шундый сөенеп утырам. Газетагызны да горурланып укыйм. Сездә барысы да яктыртыла. Тәрбия дә, дин дә, хатын-кызлар турында да күп мәгълүмат алам.

Кукмарадан коллегабыз Лилия Нургалиева үз язмасының героена рәхмәтле. Сәбәпләрен үзе сөйләде.

– Язмам герое Райнур хәзрәтнең вәгазьләрен тыңлап, минем тормыш иптәшем дә дин юлына кереп китте. Бу сүзләрне сөйләгәндә үк елыйсым килә. Хәзрәттән нур бөркелә, ди аның турында ирем. Конкурс турында белеп алгач, нәкъ тә аның турында язам, дидем. Хәер, безнең Кукмарада көчле хәзрәтләр күп. Әмма күз алдымда Райнур хәзрәт булды, – диде Лилия Нургалиева.

Илмира Салихҗанованың язмасын жюри вәкилләре бертавыштан җиңүче итеп таныды. «Ватаным Татарстан» газетасы аңа да чит түгел икән – яратып укый торган басмасы! Һөнәре буенча – педагог-психолог.

– Мондый бәйгене оештыручыларга рәхмәт. Бу бәйгедә теләп катнаштым. Телебезнең, динебезнең сагында торган барлык дин әһелләренә дә рәхмәтемне әйтәсем килә. Авыр эшләрендә уңышларга ирешеп яшәсеннәр иде, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күркәм бәйгебезнең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе. Төгәлрәге, бер вәкиле – Әлфия ханым. Исегездә булса, 2021 елда оештырган «Шәфкать» бәйгесенең дә төп иганәчесе Бәхтияровлар иде. Күркәм гамәлләренең әҗере үзләренә меңе белән кайтсын дип телибез!

ҖИҢҮЧЕЛӘР

I урын – «Бала күңеленә ачкыч», Илмира Салихҗанова (Казан).
II урын – «Зирекленең зирәк кешесе», Мәймүнә Хәйретдинова (Яңа Чишмә).
III урыннар – «Бәхет юлы», Лилия Нургалиева (Кукмара); «Универсал», Ләйлә Хәйруллина (Питрәч, Шәле); «Исеме үк зиннәтле», Рәшит Хәбибуллин (Буа, Килдураз).

ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНЕҢ МАХСУС ПРЕМИЯСЕ

«Күпкырлы имам», Әлфинур Йосыпова (Буа).

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

11 август, 2022 ел Казан ш. №178/1565

№7 Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы һәм №14 Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә теркәлгән кандидатлар арасында төбәк (республика) дәүләт телерадиотапшырулар каналларында бушлай эфир вакытын бүлү графигы турында

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 61 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. №7 Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы һәм №14 Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә теркәлгән кандидатлар арасында төбәк (республика) дәүләт телерадиотапшырулар каналларында бушлай эфир вакытын бүлү графигын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу карарны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастыруга җибәрергә.

3. Бу карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
11 август, 2022 ел, №178/1565 карарына кушымта

№7 Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы һәм №14 Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә теркәлгән кандидатлар арасында төбәк (республика) дәүләт телерадиотапшырулар каналларында бушлай эфир вакытын бүлү графигы

				ВГТРК ФГУП филиалы – «Татарстан» ГТРК, «Россия 1» телеканалы	ВГТРК ФГУП филиалы – «Татарстан» ГТРК, «Россия 24» телеканалы	ВГТРК ФГУП филиалы- «Татарстан» ГТРК, «Радио Россия» радиоканалы	«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе АҖ, «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» телеканалы	«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе АҖ, «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалы
Бер мандатлы сайлау округы атамасы	Фамилиясе	Исеме	Атасының исеме	Сайлау алды агитация материалларының (роликларның) эфирга чыгу датасы, вакыты	Сайлау алды агитация материалларының (роликларның) эфирга чыгу датасы, вакыты	Сайлау алды агитация материалларының (роликларның) эфирга чыгу датасы, вакыты	Сайлау алды агитация материалларының (роликларның) эфирга чыгу датасы, вакыты	Сайлау алды агитация материалларының (роликларның) эфирга чыгу датасы, вакыты
№ 7 Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы	Хөснетдинов	Дамир	Фаяз улы	08.09.2022, 05:00-11:00	18.08.2022, 17:00-23:00	08.09.2022, 17:00-23:00	31.08.2022, 17:50 № 3	31.08.2022, 11:15 № 3
	Галимҗанов	Ренат	Айдар улы	25.08.2022, 11:00-17:00	25.08.2022, 17:00-23:00	18.08.2022, 17:00-23:00	31.08.2022, 17:50 № 1	17.08.2022, 11:15 № 3
	Ниязов	Рөстәм	Ибраһим улы	08.09.2022, 05:00-11:00	08.09.2022, 05:00-11:00	01.09.2022, 17:00-23:00	24.08.2022, 17:50 № 2	31.08.2022, 11:15 № 1
	Гайнетдинова	Роза	Самат кызы	01.09.2022, 05:00-11:00	01.09.2022, 05:00-11:00	08.09.2022, 17:00-23:00	07.09.2022, 17:50 № 2	17.08.2022, 11:15 № 1
	Евсеев	Кирилл	Евгеньевич	25.08.2022, 05:00-11:00	18.08.2022, 17:00-23:00	01.09.2022, 17:00-23:00	17.08.2022, 17:50 № 3	24.08.2022, 11:15 № 2
	Мөхәммәтшина	Рима	Җәмил кызы	18.08.2022, 05:00-11:00	08.09.2022, 17:00-23:00	01.09.2022, 05:00-11:00	17.08.2022, 17:50 № 1	07.09.2022, 11:15 № 2
№ 14 Пионер бер мандатлы сайлау округы	Гарипов	Рөстәм	Әмин улы	18.08.2022, 05:00-11:00	01.09.2022, 17:00-23:00	08.09.2022, 17:00-23:00	24.08.2022, 17:50 № 3	24.08.2022, 11:15 № 1
	Нәгыймова	Венера	Азат кызы	01.09.2022, 05:00-11:00	08.09.2022, 17:00-23:00	08.09.2022, 11:00-17:00	31.08.2022, 17:50 № 2	07.09.2022, 11:15 № 1
	Анисимов	Дмитрий	Владимирович	08.09.2022, 11:00-17:00	08.09.2022, 17:00-23:00	25.08.2022, 17:00-23:00	24.08.2022, 17:50 № 1	31.08.2022, 11:15 № 2
	Гуськов	Сергей	Евгеньевич	01.09.2022, 17:00-23:00	01.09.2022, 17:00-23:00	01.09.2022, 17:00-23:00	07.09.2022, 17:50 № 1	24.08.2022, 11:15 № 3
	Ефимов	Родион	Вячеславович	08.09.2022, 05:00-11:00	25.08.2022, 17:00-23:00	25.08.2022, 17:00-23:00	07.09.2022, 17:50 № 3	17.08.2022, 11:15 № 2
	Федотов	Олег	Петрович	25.08.2022, 05:00-11:00	01.09.2022, 17:00-23:00	18.08.2022, 17:00-23:00	17.08.2022, 17:50 № 2	07.09.2022, 11:15 № 3

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

11 август, 2022 ел Казан ш. № 178/1567

2022 елның июлендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның июлендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 10 август, 2022 ел, № 103 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның июлендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 10 август, 2022 ел, № 103 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2022 елның июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Скворďяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры **Песошин** Алексей Валерьевич; Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы – Казан шәһәре мэры **Метшин** Илсур Рәис улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Александр Невский ордены** белән бүләкләнде.

***

Россия тарих җәмгыяте эшчәнлегендә актив катнашуы өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры **Хәйретдинов** Рамил Равил улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ каршындагы «Яшьләр дөньясы» күппрофильле яшьләр үзәге муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Сурова** Минзинә Рафаил кызына, «Чистай шәһәренең «Статус» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Фомина** Ольга Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Агропак-Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Лениногорск шәһәре) **Азимов** Юрий Шодиевич; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы Красная Горка авыл җирлеге башлыгы **Гыйззәтуллина** Вәлия Әгъмал кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратурасының кадрлар бүлеге прокуроры **Садриев** Айдар Хәйдәр улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасының Агросәнәгать комплексы ветераннары советы рәисе **Алиев** Марс Шәриф улы, «Мәскәү дәүләт ветеринария медицинасы һәм биотехнология академиясе – К.И. Скрябин исемендәге МВА» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең хосусый зоотехния кафедрасы мөдире **Балакирев** Николай Александрович, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры урынбасары **Минһаҗева** Әлфия Җәүдәт кызы, «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе урынбасары **Никифоров** Вячеслав Васильевич, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының социаль үсеш буенча киңәшчесе **Нугайбәков** Ардинат Гали улы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең балалар өчен сөт ризыклары бүлеге баш аналитигы **Распопова** Людмила Владимировна, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Казанның җылылык челтәрләре» филиалы Ветераннар советы рәисе урынбасары **Хәйруллин** Рафаэль Корбангали улы, Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы Ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе **Юманов** Виталий Алексеевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Бөгелмә районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Камалов** Айнур Мөдәррис улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Хохорин** Олег Евгеньевичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Бөтенроссия йөзү федерациясе» иҗтимагый оешмасы президенты референты **Васильев** Сергей Викторовичка, «Фехтование буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Гафурҗанова** Элла Гыйльфан кызына, Казан шәһәренең «Авиатор» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе тренеры **Рынина** Елена Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Коммунсервис-Актаныш» җитештерү берләшмәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык челтәрләре мастеры **Исламов** Фирдәвес Баһазит улына, «ЖЭК-42» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең комплекслы хезмәт күрсәтү эшчесе **Минһаҗева** Мәдинә Габделхәй кызына, «Әлмәт-Водоканал» акционерлык җәмгыятенең автотранспорт цехы автомобиль йөртүчесе **Мочков** Владимир Константиновичка, «Төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Никитина** Наталья Николаевнага, «Уңайлы йорт» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шәрәфуллин** Рамил Рафил улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Бөгелмә механика заводының конструкторлык-технология бүлеге әйдәүче инженер-конструкторы **Гыйлаҗев** Равил Әгъзаметдин улына; «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте программа-аппарат системалары эшләү һәм мәгълүмати технологияләр бүлегенең оптик-электрон системалар эшләү лабораториясе башлыгы **Зарипов** Ренат Ислам улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Районара юл-төзелеш идарәсе – 1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Әюпов** Илһам Миннәхмәт улына; «Алексеевскдорстрой» ачык акционерлык җәмгыятенең участок башлыгы **Богатов** Сергей Анатольевичка; «Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең җитештерү-техник идарәсе башлыгы **Зыятдинова** Марианна Ивановнага; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы **Гарипов** Әсхәт Карип улына; «Нефть сәнәгате объектларын проектлау буенча Казан институты» акционерлык җәмгыятенең төзелеш бүлеге генераль планнары төркеме мөдире **Петрова** Ирина Алексеевнага; «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: 3 нче арматура цехының арматура челтәрләре һәм каркаслар эретеп ябыштыручысы **Матвеева** Наталья Васильевнага, техник контроль бүлеге төзелеш эшләнмәләре һәм материаллар контролеры **Сафина** Тәнзилә Сәмигулла кызына, электр җиһазларын төзекләндерү һәм хезмәт күрсәтү цехының электр җиһазларын төзекләндерүче һәм аларны карап тотучы электромонтеры **Якаев** Таһир Мирсәлим улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

МАННАНОВА Клара Арслан кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Документлар белән тәэмин итү идарәсенең делопроизводство бүлеге әйдәп баручы белгече Камалова Альбина Госман кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Исәнмесез! Исӓммӓ́сез!

КАРАТАЙ

Кама Тамагы районының Мордва Каратаен «эчкерсезләр авылы» диләр. Мордва милләтенең бер этник төркеме саналган каратайларның яшәеше, холык-фигыле, йолалары, үзенчәлекләре белән танышу өчен, юлга кузгалдык. Алар безне «Исаммасез!» дип, үзләренә хас самимилек белән каршы алды.

ЭЧКЕРСЕЗЛӘР АВЫЛЫ

Кама Тамагы

Мордва Каратае авылына без уттай кызу урак өстендә барып кердек. Дөресен әйтим, бу чорга хас ыгы-зыгысы, анда-санда чапкан техникасы, уңышны вакытында җыеп калырга ашыккан тынгысыз кешеләре белән гөрләп торган авылга юл тоттык дип уйлаган идек. Әмма Мордва Каратае безне, каударланмыйча, тыныч кына, үзгә тынлык белән каршы алды.

Авылга кергәндә күпер янында иске генә кое кала. Үткәннәрдән сәлам кебек ул. Төпкә чиләк төшереп, әйләндерә-әйләндерә меңгереп су эчә торган чын кое. Соңрак кына белдек: авыл аша узган юлчылар, биредә туктап, су эчә торган булган икән. Бүген инде коеның суы эчәрлек түгел. Әмма каратайлар аны үткәннең ядкаре итеп саклый. Заманында авылда шундый дүрт кое булган.

Авыл башындагы өр-яңа клуб бинасы каршына килеп туктадык. Биредә безне тәмле сүз, якты йөз, такмазалар белән милли кием кигән апалар каршы алды. Каратайларның милли ризыгы – сяканядан авыз итәргә дә насыйп булды безгә. Мордва Каратаендагы бу мәдәният учагы 2012 елда төзелгән икән. Аңа кадәр авыл 25 ел клубсыз яшәгән.

– Клубыбыз 100 урынга исәпләнгән. Халык йөри. Бер күч активистларыбыз бар. Биибез дә, җырлыйбыз да, концерт-спектакльләр дә куябыз. Авылдашларыбызның юбилейларын бергә үткәрәбез, алтын-көмеш туйларын билгеләп үтүчеләрне дә зурлап котлыйбыз. Күптән түгел Түбән Кама артистлары да театр куеп китте. «Бәрмәнчек» ансамбле дә килгәне бар, – ди клуб мөдире Ирина Окунева.

Ишекнең бие юк

Тын гына утырган авыл урамы буйлап атлыйбыз. Иске йортлар яңараклары белән чиратлашып бара. Күбесенең тәрәзәсе кадакланган инде. «Авылыбызда, нигездә, өлкәннәр яши. Урта яшьтәгеләр дә күп түгел. Яшьләр бөтенесе районга, шәһәргә китеп бетте. Авылыбызда бердәнбер бала бар. Күрше авылда 8 нче сыйныфта укый ул», – дип сөйләде мине озата барган Ирина ханым.

Каршыбызга кибеткә баручы ике әби очрады. Бик ачык, мөлаемнәр. Сине әллә кайчан белгән танышлары кебек якын итеп сөйләшәләр. Ирина Окунева исә: «Бездә бөтен кеше шундый», – дип елмая.

– Бик гади, эчкерсез кешеләр инде без. Беркатлылык та бар. Тиз ышанучан. Безнең авылда беркайчан да капка-ишекләрнең ябык торганы юк. Без аны биклисе дип белмибез дә. Юкса нинди заманда яшибез бит. «Мордва өенә эләксәң, ач китмисең» дигән гыйбарә яши бездә. Кунакчыл булуыбыз белән дә аерылып торабыз, – ди Ирина ханым.

Дөрестән дә, кайсы гына капка төбенә тукталсаң да, бер генә бикле ишек-капканы да күрмәссең биредә. Безгә юл уңаенда очраган фельдшер Татьяна Заһидуллина да, каратайлар кебек үзенчәлекле халык бөтен Татарстанда юк, дип саный. «Өлкән кеше моң-зарлы була бит инде. Мордва Каратаенда яшәүче әби-бабайлар исә зарлануның нәрсә икәнен дә белми. Хәлләре ничек кенә авыр булса да, бер зарлану сүзе ишетмисең алардан. Юк-барга үпкәләп, гаеп табып та утырмыйлар. Гомумән, каратайлар – бик сабыр халык алар», – ди Татьяна ханым. Ул үзе дә каратай милләтеннән. Күрше Ишем авылында яши, шундагы фельдшер-акушерлык пунктын җитәкли. Ике авылга хезмәт күрсәтә.

«Мордва Каратаеның бетеп баруы гына кызганыч. Авыл, туган тел, традицияләр яшәсен өчен, иң беренче чиратта теләк кирәк. Гаиләдәге мөнәсәбәт тә мөһим. Без үзебез – катнаш гаилә. Ирем – татар. Ике милләтнең дә гореф-гадәт, йолаларын үтәп яшибез. Пасха җитсә, йомырка буйыйм, Троицада үземнең туган авылыма барам, зиярәт кылам. Корбан, Ураза гаетләрендә коймак пешереп, таба исе чыгарам. Корбанын да чалабыз», – ди ул.

Мордва Каратае авылы кибетендә 26 ел сатучы булып эшләгән Юлия Глониналның гаиләсе дә катнаш. Үзе – рус милләтеннән, ире – каратай. Мәрхүм каенанасы авылдагы заманында бик данлыклы булган «Мордовские узоры» ансамблен җитәкләгән. Авылның бетеп баруына үзәк өзелә, ди Юлия.

– Элек авыл бик зур иде. Хәзер инде аның халкы каратайды, яшьләр китеп бетте. Ә авылны алар ярдәмендә генә яшәтеп була. Тел, милләтне дә алар гына яшәтә ала. Әмма эш, мөмкинлекләр булмаган авылда яшьләрне тотып булмый, билгеле. Элек ичмасам ферма бар иде. Ирем гомере буе шунда эшләде. Хәзер анысы да юк. Хәзерге вакытта Ногинскида хезмәт итүче улыбыз да, армиядән кайткач, шәһәргә китәргә җыена, – ди Юлия ханым. Туган телне саклап калу өчен, аның мәктәпләрдә укытылуы да кирәк дип саный ул. Мордва теле исә бүген Тәтеш районы мәктәбендә генә укытыла.

Карда әвәләнү – уңышка

Каратайларның бик күп милли бәйрәмнәре христианнарныкы белән аваздаш. Татарларныкына охшаш йолалары да бар икән. Печән өсте башланыр алдыннан корбанга сарык чала алар. Әмма татарлардан аермалы буларак, аның итен бүлеп таратмыйлар, үзләре өчен генә тоталар.

«Троицаны да зурлап уздырабыз. Зиратка барып, даими рәвештә каберлекләрне чистартып торабыз. Зур өмәләр ясаганда, читкә таралышкан авылдашларга да хәбәр итәбез. Алар да бу эштә бик теләп катнаша», – ди авыл халкы.

Каратайлар бакчаларында күпләп сельдерей үстерә. Алар аны «зуря» дип йөртә. Каратайларда иң изге үләннәрнең берсе санала ул. Авылдагы һәркемдә бар бу үлән. Ул начар энергияне, шайтаннарны куа дип санала. Хәтта клуб янына да шуны утыртканнар. Троица бәйрәмендә ата-ана каберенә дә куялар.

Каратайлар Раштуаны – атна буе, Троица белән Хач мануны икешәр көн бәйрәм итә. Туй алдыннан кыз елату йоласы да бар аларда. Кыз дигәннән, гүзәл затларга бәйле бер йола әле дә сакланган. «7 гыйнвар көнне төштән соң ир-атлар, өйдән-өйгә йөреп, хатын-кызларны карда әвәли. Хатын-кызны карда әвәләсәң, быел уңыш яхшы була дигән ышану яши бездә. Бу эш 8 гыйнвар көнне дә дәвам итә. Эшкә барасыңмы син, кибеткәме – анда эшләре юк. Барыбер, куып тотып, карга батыралар. Моңа беркем үпкәләми дә. Уен рәвешендә уза торган борынгыдан килгән йолабыз бит бу», – ди Нина Чекменева.

Авыл читендә – гыйбадәтханә

Мордва Каратае авылы читендә өр-яңа чиркәү балкып тора. Иске йортлар янәшәсендә аерылып, әллә кайдан үзенә җәлеп итеп тора ул. Гыйбадәтханә зур бәйрәмнәрдә ачыла икән. Ул көнне районның дин әһеле килеп укый биредә. Анда Мордва Каратае халкы гына түгел, күрше авыл кешеләре дә килгәли. Без барган көнне дә ачык иде ул. Саулык таратучы саналган Изге Пантелеймон көненә туры килдек. Бу көнне чиркәүгә 6–7 апа, әби килгән иде.

Яңа иман йорты өчен каратайлылар шушы авылдан чыккан шагыйрь, журналист Владимир Андреевка рәхмәтле. Узган ел бакыйлыкка күчкән әдип гомеренең соңгы көннәренә кадәр туган авылы өчен янып яшәгән. Авылдагы чиркәүне торгызу да – аның теләктәшлеге белән башланган эш.

Гыйбадәтханә янында зур булмаган каберлек күзгә ташлана. Үтерелгән Изге Михаилның каберлеге икән бу. Риваятьләргә караганда, Изге Михаил, әти-әнисе ниятенә каршы килеп, дин юлына кереп китә. Идел буенда үзенә часовня төзи ул. Шунда яши, гыйбадәтләрен дә шунда кыла. Озакламый аның янына берөзлексез халык агыла башлый. Изге Михаил аларга гел: «Минем гәүдәм күмелгән җирдә беркайчан да корылык, янгын, давыллар, бернинди бәла-казалар да булмаячак», – дия торган булган.

Шушы сүзе аркасында, аны көннәрдән бер көнне үтереп тә куялар. Бу Сөйки авылы кешеләре булган дип фаразлана. Алар Изге Михаилның мәетен үзләренә алып кайтып җирләп, авылларын алда телгә алынган афәтләрдән азат итәргә җыенган. Әмма ни гаҗәп: изгенең мәете салынган көймә урыныннан да селкенмәгән. Ничек кенә тырышсалар, да аны урыныннан кузгата алмаганнар. Аннары алар мәетне часовняда калдырып китеп барган. 40 көннән мәетне Мордва Каратае кешеләре табып ала да авылларындагы чиркәү төбенә алып кайтып җирли. Совет чорында бу чиркәү тулысынча җимерелгән була.

Шул рәвешле 8 июнь – Изге Михаилның үлгән көне – каратайларда изге көн санала. Бу көнне аның каберен зиярәт кылалар, чардуганына яңа кульяулыклар эләләр. Идел буендагы часовняда исә гыйбадәт кылына. Аның янында өч урыннан бәреп чыккан чишмәдән халык су ала. Бу изге су барлык авырулардан шифа санала. Монда килеп теләгән теләкләр дә тиз арада кабул була, ди каратайлар. Совет чорында бу көнне бирегә теплоходлар белән төркем-төркем кешеләр килә торган булган. Корылык елында коммунист җитәкчеләр, махсус автобус биреп, яңгыр сорап дога кылырга дип, бирегә әбиләр җибәрә торган булган. 8 июнь көнне Мордва Каратае авылындагы чиркәүдә дә гыйбадәт кылына.

Шөкер итүдән башлана

Без килгән көнне аннан чыккан апалар: «Әле ярый күңелгә тынычлык табарга шушы храмыбыз бар», – диеште. Менә шулай булганга шөкер итеп, юктан да тәм, ямь табып яши белә алар. Башка милләтләр арасында күпмедер дәрәҗәдә эреп югалсалар да, милли үзаңны, милли йөзләрен сакларга тырышалар. Әнә шунысы игътибарга лаек. Җилнең кайсы якка таба исүен чамаласалар да, төшенкелеккә бирелмиләр, яхшыга өметләнәләр.

– Элек авылда дистәләрчә гаилә яшәсә, хәзер барыбыз бер зур гаилә булып яшәп ятабыз. Бер йодрык кебек. Алай булганда бердәмлек зуррак та була әле ул. Шатлыгыбыз да, кайгыбыз да уртак. Туган көннәрне дә авыл белән бергә үткәрәбез. Ялгыз авылдашларыбызны, эшкә соңга калмасын дип, йөгереп кереп уятып чыккан чаклар да бар. Бер-беребезне һәрчак күз уңында тотабыз. Болай яшәү күңелгә үзенә бер рәхәтлек бирә, – дип шөкер итә авылның клуб мөдире.

Өмет бар әле

Каратайлар – мордва милләтенең бер этник төркеме. Икенче төрле аларны мукшылар дип тә йөртәләр. Билгеле булганча, мордва милләтенең, каратайлардан кала, эрзя дигән тагын бер этник төркеме бар. Каратайлар турында беренче тапкыр XVIII гасырда, галим И. Лепехин язмаларында телгә алына. Ул аларны мордваларның үзенчәлекле бер кабиләсе дип атый.

Каратайлар – шулкадәр кызык халык: «без – мордвалар!» дип горурланган бу кешеләр үзләре, теттереп, татарча сөйләшә, үзләре христиан динен тота. Аралашу барышында шуңа игътибар иттем: үзара да, нигездә, татар һәм рус телләрендә аралаша алар. Үзләренең туган телләрендә сөйләшкәндә дә ярты сүзләрен аңлап була, күп сүзләрен татарчалаштырып әйтәләр. Ирина ханым, минем бу уйларымны укыгандай: «Без татарлашып беттек бит инде. Кызык өчен санап карасаң, без сөйләшкәндә кулланган чиста үзебезнең сүзләр биш процент чамасы гына калгандыр», – ди ул. Каратайларның туган теле бүген нинди хәлдә икәнне әнә шуннан бик яхшы чамаларга була инде.

Әмма алар үзләре мондый төшенке уйларга бирешмәскә тырыша, яхшыга өметләнә. «Бүген авылдагы 15 йортның күбесе буш, ташландык. Ләкин бар да алай ук начар түгел әле. Соңгы елларда авылда өч яңа йорт төзелде. Кайчандыр безнең авылдан чыгып китеп, лаеклы ялга чыккач, кабат монда кайткан кешеләр бу. Болай булганда, авылыбыз бетмәс, Алла боерса», – ди шушы авылда 40 ел сыер савучы булып эшләгән Нина Чекменева.

Ата-анасы янына балалары, оныклары кайтып торыр, авылга эз суынмас, бәлки, шул рәвешле авылда яшәүчеләр саны да артып китәр, дип өметләнә каратайлылар. Юкса юклы-барлы 15 йортлык шушы авылда бүген нибары 35 кеше яши. Шуларның 30ы – каратайлар. Ә бит Мордва Каратаеның яшен дә, картын да бер йодрыкта тотып, гөрләп торган чаклары да булган. Саннарга гына күз салыйк: 1958 елда биредә бер меңләп кеше яшәгән. 1976 елда инде аларның саны 300гә калган.

Нина Чекменева сүзләренә караганда, ул елларда авыл халкы күпләп мал, кош-корт асраган. Авыл балта осталары, тимерчеләре белән дан тоткан. Әмма авылда эш булмау сәбәпле, яшьләр акрынлап шәһәргә китә башлый. Гөрләп торган 133 хуҗалыклы авылда 1990 нчы еллар башына инде 78 йорт кына кала. Авылдагы башлангыч мәктәп тә ябыла.

Сүзлек

Исәнмесез! – **Исӓммӓ́сез!**	Ир – **Ир**
Исән-сау – **Исӓ́м-сав**	Хатын – **Катьі́н**
Туганнар – **Туганла́р**	Исәпләү – **Исӓплӓ́в**
Нәсел – **Нӓсе́ль**	Авыл – **Авы́л**

Тәмле булсын!

СЯКАНЯ (РЕЦЕПТ)

(каратайларның милли ризыгы)

Кирәк: *пилмән камыры, эчлеккә – гөмбә, суган, каймак (чама белән).*

Эш тәртибе: гөмбә, суганны кыздырып, каймак белән болгатабыз. Пилмән камыры басабыз. Аннары шуны тарталетка кебек ясап, тозлы суда пешереп алабыз да, эченә шушы гөмбә катнашмасын тутырабыз. Бик җиңел һәм тәмле кабымлык килеп чыга!

Сәхифәне Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 317

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+